ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2017 елның 16 нчы феврале**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 302**

2017 елның беренче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында айлык юлда йөрү өчен балалар билетын бирү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 1 п., 5 п., Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 нчы статьясындагы 1 п. каралганча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының Гари поселогында һәм Загородная урамында яшәүче гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 сыйныф укучыларына айлык юлда йөрү өчен балалар билетын таратуны гамәлгә кертергә.
2. «Волна»микрорайонында яшәүче күп балалы гаиләләрдән булган Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 сыйныф укучыларына айлык юлда йөрү өчен балалар билетын таратуны гамәлгә кертергә.
3. 2017 елның 1 нче гыйнварыннан 2017 елның 28 нче февраленә кадәр Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән бер укучыга 750 сум 00 тиен күләмендә балалар юл билетын сатып алу чыгымнарын тормышка ашыруны билгеләргә.
4. 2017 елның 01 нче мартыннан 2017 елның 31 нче мартына кадәр Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән бер укучыга ай саен 500 сум 00 тиен күләмендә балалар юл билетын сатып алу чыгымнарын тормышка ашыруны билгеләргә.
5. Зеленодольск муниципаль районының Гари поселогында һәм Загородная урамында яшәүче гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 сыйныф укучылары; «Волна» микрорайонында яшәүче күп балалы гаиләләрдән булган Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 сыйныф укучылары исемлеген расларга.

6. «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесенә Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында айлык юл билетын бирү чыгымнарын финанслауны гамәлгә ашырырга.

7. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы-җитәкчесе урынбасарына айлык балалар юл билетын таратуның үтәлешен исәпкә алуны һәм контрольдә тотуны тәэмин итәргә.

9. Гомуми белем бирү оешмалары директорларына айлык балалар юл билетын сатып алу эшен оештырырга, бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалануны тәэмин итәргә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Х. Сәхибуллин